**ГЛАВА СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Суксу, ул. Школьная, 9А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9А

тел./факс 8(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**25 март 2024 ел** **№3**

**Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Суксу торак пунктында авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 06 октябрендәге Федераль законның 25.1, 56 статьяларына ярашлы № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе, нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Суксу торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 05.04.2024 елга билгеләргә. Үткәрү вакыты 13 сәгать 00 минутта. Утырыш урыны: ТР, Биектау районы, Суксу авылы, Комсомол урамы, 19а йорт (Мәдәният йорты).

1.1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Суксу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 01 ноябрендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы: «2024 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Биектау районы Суыксу авыл җирлеге Суксу торак пунктында теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- рөхсәтсез чүплекне бетерү;
- тракторны тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, хезмәт хакы);
- урам яктыртычны ремонтлау;
- Балалар мәйданчыгын сатып алу һәм төзекләндерү;
- Бөек Ватан сугышында һәлак булган катнашучыларга һәйкәлне ремонтлау»

2023 елның 01 ноябрендәге 6 номерлы карарда күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эшләргә үзгәртү:

- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (рөхсәтсез чүплекне бетерү)

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (тракторны тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, хезмәт хакы))

- урам яктырту җайланмасы (урам яктыртуны ремонтлау)

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгын сатып алу һәм төзекләндерү)

- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында һәлак булган катнашучыларга һәйкәлне ремонтлау)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев